| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 ноябрь, 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 18 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Иске Чәчкаб авылы, Клуб урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2023 елның 24 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Иске Чәчкаб авылы, Үзәк урамы, 25А йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2023 елның 27 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Иске Чәчкаб авылы, Үзәк урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә.
4. 2023 елның 28 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Иске Чәчкаб авылы, Клуб урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- территорияләрне торак пунктның санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру::*

- материаллар сатып алып, су башнясын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү;
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:*

- материаллар сатып алып, зират территориясен саклау төзекләндерү һәм ремонтлау.»

« РИЗА»                                        «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы                    А.И. Рәхмәтуллин